**Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы**

БОЕРЫК

24.03.2015 Казан ш. №21-53-18

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының аерым боерыкларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының норматив-хокукый актларын законга туры китерү максатыннан чыгып, боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының 17.11.2010 ел, № 21-53-80 боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы бюджет һәм автоном учреждениеләренең лицевой счетларын ачу һәм алып бару тәртибенә (Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының 15.06.2011 ел, № 21-53-44, 17.02.2012 ел, № 21-53-5, 25.12.2014 ел, № 21-53-64 боерыклары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Казначылык департаменты бюджет һәм автоном учреждениеләрнең средстволарын учетка алу өчен эшчәнлек төрләре ягыннан “Дәүләт милкендәге (федераль милектән тыш) оешмалар счетлары. Финанс оешмалары” 40601баланс счетында (алга таба - 40601 счет) лицевой счетлар ача. 40601 счетлары бюджет учреждениеләре өчен Татарстан Республикасы Милли банкында, автоном учреждениеләр өчен – кредит оешмаларында ачыла.”;

2.2.1 пунктка түбәндәге эчтәлектәге абзацлар өстәргә:

«хезмәт хакы һәм өстәмә исәпләүләр буенча финанс-хуҗалык эшчәнлеге планын үтәү өчен билгеләнгән лицевой счет (алга таба – хезмәт хакы буенча лицевой счет);

мәҗбүри медицина иминиятләштерүе средстволары белән операцияләр учеты өчен билгеләнгән лицевой счет (алга таба – ОМС средстволары белән лицевой счет);

вакытлыча эш итүгә бирелгән средстволары учеты өчен билгеләнгән лицевой счет (алга таба — вакытлыча эш итүгә бирелгән средстволар буенча

лицевой счет).”;

2.2.2 пунктка түбәндәге эчтәлектәге абзацлар өстәргә:

«хезмәт хакы һәм өстәмә исәпләүләр буенча финанс-хуҗалык эшчәнлеге планын үтәү өчен билгеләнгән лицевой счет (алга таба – хезмәт хакы буенча лицевой счет);

мәҗбүри медицина иминиятләштерүе средстволары белән операцияләр учеты өчен билгеләнгән лицевой счет (алга таба – ОМС средстволары белән лицевой счет);

вакытлыча эш итүгә бирелгән средстволар учеты өчен билгеләнгән лицевой счет (алга таба — вакытлыча эш итүгә бирелгән средстволар буенча лицевой счет) ;

вакытлыча эш итүгә бирелгән средстволар (авыруларның пенсияләре) учеты өчен билгеләнгән лицевой счет (алга таба — пенсия лицевой счеты).”;

3.2 пунктта:

бишенче абзацта «А» – автоном» дигән сүздән соң «; «Ф» – бюджеттан тыш фондлар средстволары; «П» – пенсия; «Р» – вакытлыча эш итүгә бирелгән средстволар буенча » дигән сүзләрне өстәргә;

алтынчы абзацта «О» – аерым» дигән сүздән соң «З» –хезмәт хакы» дигән сүзне өстәргә;

4.3 пунктның беренче абзацында “биш эш көне эчендә” дигән сүзләрне “өч  эш көне эчендә” дигән сүзләргә алыштырырга;

4.4 пунктта “биш көн эчендә” дигән сүзләрне “өч көн эчендә” дигән сүзләргә алыштырырга;

8.1 пунктның беренче абзацында “бюджеттан тыш чыганаклар буенча” дигән сүзләрдән соң “ОМС средстволары белән лицевой счетта, хезмәт хакы буенча лицевой счетта, пенсия лицевой счетында, вакытлыча эш итүгә бирелгән средстволар буенча лицевой счетта,” дигән сүзләрне өстәргә;

8.2 пунктның беренче абзацында “ОМС средстволары белән лицевой счетта, хезмәт хакы буенча лицевой счетта, пенсия лицевой счетында, вакытлыча эш итүгә бирелгән средстволар буенча лицевой счетта,” дигән сүзләрне өстәргә;

9.3 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакwиядә бәян итәргә:

«9.3. Бюджет һәм автоном учреждениеләрнең лицевой счетларыннан өземтәдә чагылдырыла:».

2. Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының 31.12.2010 ел, № 21-53-92 боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы бюджет

учреждениеләре средстволары хисабына касса түләүләрен үткәрү тәртибенә ( Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының 25.12.2014 ел, № 21-53-64 боерыгы нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Казначылык органнары тарафыннан, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының 17.11.2010 ел, № 21-53-80 боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Бюджет һәм автоном учреждениеләренең лицевой счетларын ачу һәм алып бару тәртибе нигезендә, лицевой счетлар ачыла .»;

Тәртиптә тиешле килешләрдәге «№ 40603 счет» сүзләрен тиешле килешләрдә «№ 40601 счет» сүзләренә алыштырырга.

3. Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының 31.12.2010 ел, № 21-53-92 боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы автоном учреждениеләре средстволары хисабына касса түләүләрен үткәрү тәртибенә (Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының 25.12.2014 ел, № 21-53-64 боерыгы нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Казначылык органнары тарафыннан, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының 17.11.2010 ел, № 21-53-80 боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Бюджет һәм автоном учреждениеләренең лицевой счетларын ачу һәм алып бару тәртибе нигезендә, лицевой счетлар ачыла .»;

Тәртиптә тиешле килешләрдәге «№ 40603 счет» сүзләрен тиешле килешләрдә «№ 40601 счет» сүзләренә алыштырырга.

4. Бу боерыкны Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы Казначылык департаментына Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында дәүләт теркәвенә алу өчен җибәрергә.

5. Бу боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы финанс министрының беренче урынбасары - министрлыкның Казначылык департаменты директоры М.Д.Фәйзрахмановка йөкләргә.

Министр Р.Р.Гайзатуллин